Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

10.02.2021 Менделеевск ш. № 79

Менделеевск муниципаль районының
авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче
аерым категория гражданнарына
торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен
түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының авыл җирлегендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Министрлар Кабинетының "Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында" 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы Карары нигезендә, "Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында" 2005 елның 7 июнендәге 251 номерлы карары нигезендә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр белгечләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын түбәндәге категория гражданнарга күрсәтергә:

— мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе хезмәткәрләренә торак, җылылык, ут өчен түләү – торак мәйданының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә һәм коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары күләмендә торак, җылылык, ут өчен түләү чыгымнарының 100 процент күләмендә. Әгәр авыл җирендә урнашкан мәгариф учреждениеләрендә, мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән һәм шунда яшәгән, шулай ук Россия Федерациясе системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмаса, әлеге социаль ярдәм чарасы пенсиягә чыккан хезмәткәрләр артыннан сакланып кала.

2. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларын куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм

чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче вәкаләтле орган күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә дип билгеләргә.

3. Бюджет формалаштырганда "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы" МКУ район бюджетының өстәмә чыгымнарын каплау чыганакларын билгеләргә.

4. Муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын алу мөмкинлеге турында тиешле аңлату эшләре алып барырга.

5. «Менделеевск муниципаль районы авыл җирлегендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1233 номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.И.Ямалеевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Абдуллин

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

ТР ММР БК җитәкче урынбасары Е.И. Ямалеева

ТР ММР БК юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева